| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТИМЯШЕВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТИМӘШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 25 феврале № 1

Тимәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2018 елның 19 сентябрендәге 16 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 13 ноябрендәге 83-ЗРТ номерлы «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. “Тимәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2018 елның 19 сентябрендәге 16 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктта «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгының «Административ беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 16нчы номерлы карарындагы кушымтада «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) таблицада «Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.2 статьясы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы/ “Тимәш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре)»; - “Тимәш авыл

җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) таләпләрен үтәмәү һәм "Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.7 статьясы муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу/ «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы; - «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) сүзләре кергән юлларны төшереп калдырырга.

2. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны Тимәш авыл җирлеге территориясендә урнашкан Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорт (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 йорт (мәдәният йорты), нефтьүткәргеччеләр ур., 20 йорт (Ромашкино РРНУның утырышлар залы), Киров ур., 1А йорт («Ласточка» балалар бакчаксы), Лесная ур., 20 йорт, Лесная ур., 33нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда һәм “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

“Тимәш авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Башлыгы Р.М. Сираев